**ГЛАВА КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422626 Хәерби авылы,
Урман урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2024 елның 29 октябре** **6 номер**

# КАРАР

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Хәерби торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1.2024 елның 8 ноябрендә 15.00 сәгатькә Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Хәерби торак пунктында Ленин урамы 2 йорт адресы буенча Болотная ур., Урман ур., Елга ур., Степная ур., Горький ур., Ленин ур., Спартак ур., Яшьлек ур., Овражная урамы, Бәхетле ур., Илфар Билалов ур., Гвардия ур., Пионер ур., Татарстан ур., Мәктәп ур., авыл Советы ур., Яшьләр урамы, Чапаев урамы, Дальняя урамы, Гәрәй урамы, Отрадная урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге Хәерби торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү.

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган

башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау буенча эшләр өчен түләүгә юллау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Хәерби авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында рәсми кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Зинәтуллин Р.К.**